ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 148 от «12» 04 2023 г.

Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 13 декабрендәге 594 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә җайга салына торган тарифлар буенча автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны җайга салу һәм идарә итү системасын оештыру һәм камилләштерү, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы чикләрендә транспорт хезмәтләренең тигез мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, 2015 елның 13 нче июлендәге «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны даими йөртүне оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 220-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 13 декабрендәге 594 номерлы карары (алга таба –Карар) белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә җайга салынулы тарифлар буенча даими рәвештә муниципаль маршрутлар буенча гомуми файдаланудагы транспортта пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга киткән чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручыларга субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Карарның Преамбуласындагы «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирүне көйләүче норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында» 2016 елның 6 сентябрендәге 887 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән» сүзләрен төшереп калдырырга:

0000011721

1.2. 1 нче кушымтаның 3.1 пунктындагы 9 нчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучы чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик заты капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

1.3. 1 нче Кушымтаның 7.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Вәкаләтле орган һәм муниципаль финанс контроле органы субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын үтәүне тикшерә, шул исәптән аларны бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә.»

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә җайга салынулы тарифлар буенча даими рәвештә муниципаль маршрутлар буенча гомуми файдаланудагы транспортта пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга киткән чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручыларга субсидияләр бирү тәртибенә 2 нче Кушымта булып килүче Комиссия Составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. Комиссия составынан комиссия рәисе И.М. Дәрҗемановны чыгарырга.

2.2. Комиссия составына Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе О. Н.Павловны комиссия рәисе итеп кертергә.

3. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А. Х. Әгъләмовка йөкләргә.

Җитәкче О.Н.Павлов